| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 23.10.2015 г. Казань № 10-23/кс

Республика житештерү оешмасы «Таткоммунэнерго« АЖе өчен эчергә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне башкаручы Республика житештерү оешмасы «Таткоммунэнерго» АЖе өчен эчәргә яраклы суга тарифларны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 сентябреннән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне башкаручы Республика житештерү оешмасы «Таткоммунэнерго» АЖе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
кушымта
23.10.2015 № 10-23/кс

Салкын су белән тәэмин итүне башкаручы Республика җитештерү оешмасы «Таткоммунэнерго» АҖе
өчен эчәргә яраклы суга тарифлар

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм (яисә) су агызуны башкаручы оешмалар, муниципаль берәмлекләр атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы) сум/куб.м |
|---|---|---|
| | Әгерҗе муниципаль районы | |
| 1 | Республика җитештерү оешмасы «Таткоммунэнерго» АҖе | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 25,70 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 21,78 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге